| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ШИШИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ ШЕҢШЕҢӘР<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |

| | |
|---|---|
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ<br>28.03.2023 г. | КАРАР<br>№5 |

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә файдаланылган терекөмешле лампаларны туплану урынын (урыннарын) булдыру һәм кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында**

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 24.06.1998 № 89-ФЗ, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 10.01.2002 №7-ФЗ, «Энергияне сак тоту һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 23.11.2009 № 261-ФЗ Федераль законнарга ярашлы рәвештә, 06.10.2003 № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», Татарстан Республикасының 28.07.2004 ТРЗ№45 «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында», Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28.12.2020 № 2314 «Тиешсез җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм аларны урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырту җайланмалары, электр лампалары ягыннан җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында»гы карары нигезендә, карар итәм:

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм вакытлыча урнаштыру урынын билгеләү турында» 22.12.2021 №16 карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә файдаланган терекөмешле лампалар туплану урынын (урыннарын) билгеләргә: Шеңшеңәр авылы,Г.Тукай урамы,166 йорт адресы буенча урнашкан МТП территориясендә урнашкан бина ; Ор авылы,М.Җәлил урамы,138 йорт адресы буенча урнашкан амбар территорисендәге бина.

3. Милекчеләре, яллаучылары, кулланучылары булган күпфатирлы йортларда тиешсез җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган, кулланучылар файдаланган терекөмешле лампалар туплану урыннары яктырткыч җайланмалар, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28.12.2020 № 2314 карары белән расланган кагыйдәләренең 4 пункты нигезендә билгеләнә.

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән терекөмешле лампаларның туплану урыннары, әгәр күпфатирлы йортларда терекөмешле лампаларның туплану урыннарын оештыру мөмкин булмаса, бу йортларда кулланучылар файдаланган терекөмешле лампаларны туплану урыны да булып тора.
5. Кулланучыларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампалар тупланган урынның (урыннарның) урнашуы турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнары биналарында урнаштыру юлы белән хәбәр итәргә.
6. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталы" интернет – ресурсында ( http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) һәм Шеңшеңәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
7. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Шеңшеңәр авыл җирлеге башлыгы: Р.Х.Салихҗанов